Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл җирлеге Мөгезле-Елга авылында гражданнарның җыены
нәтиҗәләре турындагы карар

26 ноябрь 2022 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «ТатарстанРеспубликасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Мөгезле-Елга авылында гражданнар җыены йомгаклары буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында»2022 елның 25 ноябрендәге хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Мөгезле-Елга авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Мөгезле-Елга авылында 2022 елның 25 ноябрендәгражданнар җыены узмаган дип танырга.

2.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга,Мөгезле-Елга авылы, Родниковая урамы, 14 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә,шулай ук «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Н.А.Миназева